МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

«03» октября 2013 г.

№ 3668/13

Казань

# Каюм Насыйри исемендәге премия бирү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 нче елның 19 нчы июненнән һәм 2010 нчы елның 30 нчы декабреннән кабул ителгән “Каюм Насыйри исемендәге премия турында”гы 396 һәм 1141 нче номерлы карарлары нигезендә лаеклы булган педагогик коллективларга, мәктәпкәчә белем бирү, гомуми урта, башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренә ел саен Каюм Насыйри исемендәге премия бирелә.

Премия милли мәгарифне үстерүдә һәм Татарстан Республикасы халыклары милли мәдәниятенең традицияләренә таянып, белем һәм тәрбия бирүдә яхшы нәтиҗәләргә ирешкән, милли белем учреждениеләре өчен укыту-методик кулланмалар һәм фәнни хезмәтләр язган өчен билгеләнә.

2013 нче елда Каюм Насыйри исемендәге премиягә 24 эш кабул ителде. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 нче елның 1 нче мартыннан 793/13 нче боерыгы нигезендә тәкъдим ителгән кандидатураларның эшчәнлеге комиссия тарафыннан өйрәнелде. Каюм Насыйри исемендәге премия билгеләү комиссиясенең утырышы 2013 нче елның 27 нче сентябрендә үткәрелде. Яшерен тавыш бирү юлы белән Каюм Насыйри исемендәге премиягә лауреатлар сайланды һәм комиссия карары кабул ителде.

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге премияне билгеләү комиссиясе нәтиҗәләренә нигезләнеп, **БОЕРЫК БИРӘМ**:

1. 2013 нче елда Каюм Насыйри исемендәге премияләрне түбәндәге педагогик коллективларга һәм аерым шәхесләргә бирергә:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе “Бим гомуми урта белем бирү мәктәбе” коллективына;

- Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының татар телендә укыту буенча методик кабинеты әгъзаларына

(Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының корылма механикасы кафедрасы профессоры, методик кабинет мөдире Шакирҗанов Рәшит Әгъләм улы,

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты Транспорт корылмалары институтының гомум инженерлык факультеты деканы, математика кафедрасы профессоры Туктамышов Наил Кадыйр улы,

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының теоретик механика кафедрасы профессоры Камалов Абрик Закир улы);

- Яр Чаллы шәһәре мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен муниципаль автономияле белем бирү учреждениесе “64 нче прогимназия”нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Галиева Наилә Гали кызына;

- Казан шәһәре Вахитов районы 27 нче гимназиясенең география һәм гарәп теле укытучысы Мөхәммәтҗанов Ильяс Мулланур улына.

2. Лауреатларга “Каюм Насыйри исемендәге бүләк” билгесен тапшырырга.

3. 2013 нче елда Каюм Насыйри исемендәге премиягә тәкъдим ителгән хезмәткәрләрнең һәм коллективларның нәтиҗәле эшен билгеләп үтәргә, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының дипломы белән бүләкләргә (1 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (М.Ә.Дәүләтшина) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 нчы елның 30 нчы декабреннән кабул ителгән “Каюм Насыйри исемендәге премия турында”гы 1141 нче номерлы карарына нигезләнеп, лауреатларга премия бирергә.

5. Боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы мәгариф
һәм фән министры

Э.Н. Фәттахов

И.Ж. Гомәрова, 292–27–74

*1 нче кушымта*

2012 нче ел өчен Каюм Насыйри исемендәге премиягә тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеге

| | |
|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе “Риторика” һәм “Әдәби уку” укыту-методик комплектлары авторлар коллективы (Гарифуллина Миләүшә Ярулла кызы, Сафиуллина Гөлсинә Мидхәт кызы, Хәсәнова Фәридә Фирдәвес кызы, Вәлиев Мөдәррис Харис улы) |
| 2 | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе “8 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе” татар теле һәм әдәбияты укытучылары методик берләшмәсе |
| 3 | Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының 1нче лицеенның татар теле һәм әдәбияты укытучылары методик берләшмәсе |
| 4 | Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының татар телендә укыту буенча методик кабинеты әгъзалары:<br>- Шакирҗанов Рәшит Әгълә улы, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының корылма механикасы кафедрасы профессоры, методик кабинет мөдире<br>- Туктамышов Наил Кадыйр улы, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты Транспорт корылмалары институтының гомум инженерлык факультеты деканы, математика кафедрасы профессоры<br>- Камалов Абрик Закир улы, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының теоретик механика кафедрасы профессоры |
| 5 | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре 52 нче «Әкият» балалар бакчасы тәрбиячеләре Насыйрова Сүрия Әхәт кызы, Габдрахманова Кадрия Фәлих кызы |
| 6 | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе ТР муниципаль бюджет учреждениесе “Мәгълүмати-методик үзәк” методисты Шәфыйкова Мәхтүмә Сәләхетдин кызы |
| 7 | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен муниципаль автономияле белем бирү учреждениесе “64 нче прогимназия”нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Галиева Наилә Гали кызы |
| 8 | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Гали Акыш исемендәге 84нче лицей-интернатының татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сәрвәрова Рәдинә Миңнерәсил кызы |
| 9 | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре “Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче гимназия” муниципаль гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Вәлиева Суфия Васил кызы |
| 10 | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе “29 нчы гимназия”нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Исхакова Рима Мөхәррәм кызы |
| 11 | Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин районы ГБМБУ “7 нче гимназия”нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Нәбиуллина Тәслимә Гинияt кызы |
| 12 | Татарстан Республикасы Казан шәһәре Вахитов районы 27 нче гимназиясенең география һәм гарәп теле укытучысы Мөхәммәтҗанов Ильяс Мулланур улы |
| 13 | Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин районы “Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 85 нче урта гомуми белем мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, |

| | |
|---|---|
| | милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары Миндубаев Илсур Мансур улы |
| 14 | Татарстан Республикасы «Советлар Союзы герое Павел Семенович Ханжин исемендәге Тәтеш 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гасимова Светлана Иргиз кызы |
| 15 | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең 43 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хөснуллина Резидә Рәфыйк кызы |
| 16 | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең 43 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хөснуллина Алсу Рифгат кызы |
| 17 | Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Биеш гомуми урта белем мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хисамова Фирая Мөхәммәт кызы |
| 18 | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы “Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 1 нче урта гомуми белем мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең математика укытучысы Вараксина Екатерина Макаровна |
| 19 | Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин районының “Татар телендә белем бирүче 155 нче гимназия” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе |
| 20 | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе “Бим гомуми урта белем бирү мәктәбе” |
| 21 | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “ Ютазы урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе |
| 22 | Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының “159 нчы лицей” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе |
| 23 | Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров районының “Татар телендә гомуми белем бирүче 3 нче гимназиясе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе |
| 24 | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы “Катнаш төрдәге “Салават күпере” балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе |